ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2025 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтү турында» 2012 елның 2 ноябрендәге 73-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); 2014, № 1 – 2, № 12 (II өлеш); 2016, № 5; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 44 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш); 2022, № 17 (I өлеш); 2023, № 3 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 56 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш); 2025, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлешнең 4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) инвалид балалар, ятим балалар, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан булган затлар, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затлар (төп гомуми, урта гомуми белем бирү уку-укыту программалары, төп һөнәри уку-укыту программалары һәм (яисә) эшче һөнәрләре, хезмәткәрләр вазыйфалары буенча һөнәри әзерлек программалары буенча уку чорында ата-анасы яисә бердәнбер атасы йә анасы вафат булган 18 яшьтән алып 23 яшькә кадәрге затлар), шулай ук, әлеге затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итүгә һәм яклауга бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсәләр, аларның законлы вәкилләре һәм вәкилләре;»;

2) 2 өлешнең $10^2$ пунктында «затларның» сүзеннән соң «һәм уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларның» сүзләрен өстәргә;

3) 3 өлешнең 2 пунктында:

а) «г» пунктчасында «затларга» сүзеннән соң «, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларга» сүзләрен өстәргә;

б) «д» пунктчасында «затларның» сүзеннән соң «, уку чорында ата-анасын яисә бердәнбер атасын йә анасын югалткан затларның» сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2025 ел, 10 октябрь
№ 72-ТРЗ